# КАРАР

## Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлегенең Шармаш торак пунктының гражданнар җыены буенча

**2019 елның 7 декабре** **Шармаш авылы**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, 2019 елның 7 декабрендә Шармаш торак пунктында узган гражданнар җыенының тавыш бирү нәтиҗәләре белән хисап комиссиясе беркетмәсе төзелде, «Сез ризамы, Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлегенең Шармаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда гражданнарның 500 сум күләмендә үзара салымын кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны чираттагы эшләрне башкару буенча юнәлтергә:

- игъланнар өчен щит сатып алу;
- балалар мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру;
- юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү) әлеге урамнар буенча: Школьная, Заречная, Бобровка, Киров;
- юлларны кардан чистарту;
- Заречная урамы буенча юл аша чыгу өчен 500 см диаметрлы торба сатып алу һәм урнаштыру;
- 76 мм диаметрлы үзлегеннән изоляцияләнгән чыбык, насос-компрессор торбалар сатып алу һәм урнаштыру, каптажның электр линиясен яңарту өчен килешү буенча эшләр өчен түләү;
- зиратта каты көнкүреш калдыклары өчен алты контейнер сатып алу.

« РИЗА» «КАРШЫ»?».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында хисап комиссиясе беркетмәсе нигезендә:

Җыенда катнашучыларның сайлау хокукына ия булучылары исемлегенә 268 кеше кертелгән;

җыенда катнашучыларның тавыш бирүчеләре саны 135 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар өчен түбәндәгеләр билгеләнде:

гражданнар җыенында 135 катнашучы «Риза» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлегенең Шармаш торак пунктында гражданнар җыены булып узды, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес.

2. Мәсьәлә буенча карар кабул итәргә: «Сез ризамы, Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлегенең Шармаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда гражданнарның 500 сум күләмендә үзара салымын кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны чираттагы эшләрне башкару буенча юнәлтергә:

- игъланнар өчен щит сатып алу;

-балалар мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру;

- юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү) әлеге урамнар буенча: Школьная, Заречная, Бобровка, Киров;

- юлларны кардан чистарту;

- Заречная урамы буенча юл аша чыгу өчен 500 см диаметрлы торба сатып алу һәм урнаштыру;

- 76 мм диаметрлы үзлегеннән изоляцияләнгән чыбык, насос-компрессор торбалар сатып алу һәм урнаштыру, каптажның электр линиясен яңарту өчен килешү буенча эшләр өчен түләү;

- зиратта кабул ителгән каты көнкүреш калдыклары өчен алты контейнер сатып алу-кабул ителгән.

3. Җыен нәтиҗәләре турында әлеге карарны, гамәлдәге законнар нигезендә, шул исәптән Үзәк авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Үзәк авыл җирлеге Башлыгы: В. Н. Котников